ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы территориясендә тонусны күтәрә торган алкогольсез (шул исәптән энергетик) эчемлекләр сатуга тыюлар һәм чикләүләр турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 24 декабрендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон «Балигъ булмаганнарга тонусны күтәрә торган алкогольсез (шул исәптән энергетик) эчемлекләр сатуга тыю турында һәм «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның төп принциплары турында» Федераль законның 44 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2024 елның 8 августындагы 304-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) нигезендә гражданнар сәламәтлеген яклау, мондый эчемлекләр куллanудан зыян килүне кисәтү максатларында Татарстан Республикасы территориясендә тонусны күтәрә торган алкогольсез (шул исәптән энергетик) эчемлекләр сатуга тыюлар һәм чикләүләр билгели.

2 статья. **Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр**

Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр Федераль закондагы мәгънәләрендә кулланыла.

3 статья. **Тонусны күтәрә торган алкогольсез (шул исәптән энергетик) эчемлекләр сатуга тыюлар һәм чикләүләр**

1. Татарстан Республикасы территориясендә белем бирү эшчәнлеген, медицина эшчәнлеген, мәдәният, физик культура һәм спорт өлкәсендә эшчәнлекне турыдан-туры гамәлгә ашыру өчен кулланыла торган биналарда, төзелмәләрдә, корылмаларда, урыннарда тонусны күтәрә торган алкогольсез (шул исәптән энергетик) эчемлекләр сату тыела.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тонусны күтәрә торган алкогольсез (шул исәптән энергетик) эчемлекләр сатуны түбәндәге очракларда чикләргә хокуклы:

1) «Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар турында» 2004 елның 19 июнендәге 54-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә оештырыла торган гавами чараларны үткәрү вакытында гражданнар күпләп җыела торган урыннарда һәм мондый урыннар янәшәсендәге чикләре Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан күрсәтелгән чаралар үткәрүне килештергәндә билгеләнә торган территорияләрдә;

2) «Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 2007 елның 4 декабрендәге 329-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә оештырыла торган физик культура чаралары һәм спорт чаралары, спорт ярышлары үткәрү вакытында.

4 статья. **Тонусны күтәрә торган алкогольсез (шул исәптән энергетик) эчемлекләр сату өлкәсендә региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге)**

1. Федераль законның 2 һәм 3 статьялары һәм әлеге Закон белән билгеләнгән тыюларны һәм чикләүләрне үтәүгә региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тонусны күтәрә торган алкогольсез (шул исәптән энергетик) эчемлекләр сату өлкәсендә региональ дәүләт контролен гамәлгә ашыруга вәкаләт биргән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан башкарыла.

2. Тонусны күтәрә торган алкогольсез (шул исәптән энергетик) эчемлекләр сату өлкәсендә региональ дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) предметы оешмалар, индивидуаль эшкуарлар, юридик зат төземәгән крестьян (фермер) хуҗалыклары, Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар тарафыннан Федераль законның 2 һәм 3 статьялары һәм әлеге Закон белән билгеләнгән тыюларны һәм чикләүләрне үтәүдән гыйбарәт.

3. Тонусны күтәрә торган алкогольсез (шул исәптән энергетик) эчемлекләр сату өлкәсендә региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге) турында нигезләмә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

5 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон 2026 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2026 ел, 03 гыйнвар
№ 5-ТРЗ